РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.07.2019 № 699-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының,
2016 нчы елның 21 нче октябрендәге
1303-п номерлы карары белән расланган,
Саба муниципаль районының
белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы
мәгариф оенімалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен)
аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасынын,2019 нчы елныц 5 нче июнендәге - ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатыннан норматив хокукый актны үзгәртү турындагы таләбе нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының, “Саба муниципаль районыц белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турында нигезләмәсен раслау хакында” гы 2016 нчы елныц 21 нче октябрендәге 1303-п номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмәгә, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.6. пунктын түбәндәге үзгәртелгән редакциядә бәян итәргә:

“1.6. Җитәкче вазифасына дәгъва итүче җитәкчеләрне һәм затларны аттестацияләү, кагыйдә буларак, алар белән хезмәт килешүе төзелгәнче, хезмәт килешүе төзелгән очракта – хезмәткәр өчен хезмәт килешүе шартлары белән билгеләнгән сынау срогы чыкканчы үткәрелә”.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны “ТР Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУ начальнигы И.Ф. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов